| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ |

**Карар** **Решение**

№ 2-19 от «26» декабря 2022 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлегенең Генераль планын раслау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Премьер – министры А.В.Песошин белән килештерелгән Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлегенең Генераль планы проектына 2022 елның 20 декабрендәге № 10-53/15857г бәяләмәне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлегенең Генераль планын әлеге карарга кушымталар нигезендә расларга.

2. Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлегенең Генераль планын Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының интернет челтәрендә http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Интернет-телекоммуникация челтәрендә Мамадыш муниципаль районы http://mamadysh.tatarstan.ru адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2016 елның 3 октябрендәге «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Омар авыл җирлегенең генераль планы турында» №9-11 карарын үз көчен югалтты дип санарга (үзгәрешләр кертү турында).

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Советының җирле үзидарә, аграр сәясәт, җирдән файдалану һәм экология буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Район башлыгы,
муниципаль район
Советы рәисе А.П. Иванов